# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Хуҗәмәт авыл җирлегенең Бакчасарай торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**19.11.2020ел.** **№1**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 19 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча төзелде: "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Бакчасарай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлар, БВС катнашучылар, БВС катнашучыалрның тол хатыннары, Россия Армиясенә вакытлы хезмәткә алынучылардан башка) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

1. Бакчасарай торак пунктында Лесная урамында янгын сүндерү гидранты урнаштыру (эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 54 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 31 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 31 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Бакчасарай торак пунктында халык җыены узуын танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Бакчасарай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлар, БВС катнашучылар, БВС катнашучыалрның тол хатыннары, Россия Армиясенә вакытлы хезмәткә алынучылардан башка) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны танырга:

2. Бакчасарай торак пунктында Лесная урамында янгын сүндерү гидранты урнаштыру (эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3. Хуҗәмәт авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми

сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгы** ______________ **Вилданова Г.Г.**
(имза) (тулысынча имза)